Флёра Тарханова

# Серле дөнья



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Т21

*Юлия Щетинкина* рәсемнәре

**Тарханова Флёра**

Т21 Серле дөнья: Балалар өчен шигырьләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. — 40 бит.

Китапта шагыйрәнең нәниләр тормышындагы кызыклы ачышларны эченә алган һәм аларның әйләнә-тирә, табигать турындагы үзенчәлекле күзәтүләрен тасвирлаган яңа шигырьләре тупланды.

ISBN 5-298-01240-X

© Татарстан китап нәшрияты, 2002

# Тылсымлы кошчык





## СӨЙДЕРГЕЧ БӨТИЕ

Минем бар бер кызчыгым —
Һаман «сайрап» тора ул,
Янымнан китмәсеннәр, дип,
Төрле хәйлә кора ул.

Нәни кызымның күзләре —
Әйтерсең, зәңгәр диңгез,
Сокланып карыйбыз, аннан:
«Тфү! Күз тимәсен!» — дибез.

Чәче алтын, йөзе ай кук
Минем бу тәтиемнең,
Сандугачка, былбылга тиң
Сөйдергеч бөтиемнең.

## НӘНИ ДИЛӘ

Бик нәни булса да Дилә
Чисталыкны ярата:
Үрмәләп кенә йөрсә дә,
Бар чүпне җыеп ата,

Өстәлдә тотмый бер дә
«Артык» тәлинкә-кашык —
Сыпырып кына төшерә,
Авызың торсаң ачып.

## ТЫЛСЫМЛЫ КОШЧЫК

Магниттан да болайрак
Тарта кызым үзенә,
Елмаеп, безне сәламли,
Күренгәч тә күзенә.

Янына килеп бастыңмы —
Китәм димә, борылып,
Елаудан туктатып булмый,
Кулга алмыйча торып.

«Әббә» диеп әйтеп куйса,
Күңелләр эреп китә.
(Башка сүзне белми әле —
Сөйләшергә бик иртә).

Шулай иркәләнеп үсә
Хәйләкәр кызчыгыбыз,
Көнен-төнен сайрый торган
Тылсымлы кошчыгыбыз.



## ЯРДӘМГӘ КУША КУЛНЫ

Диана хәйран зур үсте —
Дүрт яшен дә тутырды.
Дәртләнеп сөйли башласа,
Ярдәмгә куша кулны.

Як-якка җәеп җибәрә,
Аптыраушта калганда,
Алга сузып селкеп тора,
Бик нык ачуланганда.

Курчагына һич тынгы юк —
Көн дә акыл өйрәтә:
«Ашамасаң, сөт эчмәсәң,
Үсмисең», — дип кисәтә.

Чәчкәләрне таптап киткән
Малайны да битәрли:
«Баш эшләми бу малайның,
Әллә чок-чок микән? — ди.

Бөтен җирне «этләп» йөргән
Этләргә дә эләгә:
«Дәү әни, бу маэмайларга
Туалетлар юк мәллә?»

Һәр нәрсәгә исе китә,
Бар нәрсәне төпченә,
Зурлар кебек фикер йөртә,
Булса да бик кечкенә.

Гаҗәеп йомшак күңелле —
Ярдәмгә һәрчак әзер,
Йөрмәгәне, күрмәгәне,
Белмәгәне юк хәзер.





# «ӨЙЛӘНСӘМ», НИ ДИЯРСЕҢ?

Беркөн кайткач, кызым әйтә:
— Дәү әни, син беләсеңме,
Мин бит бүген бакчада
Бер шәп малай очраттым:
Аптырамам акчага,
Квартиры бар, өч машина —
Син дә аны сөярсең,
Шул малайга иртәгә үк
«Өйләнсәм», ни диярсең?

Иртәгесен бакчасыннан
Кайтып керде борчылып:
— «Өйләнмәскә» булдым эле
Чабып йөри сызгырып,
Чәчтән тарта, төртеп ега,
Бигрәк инде әдәпсез,
Бер дә харап елак тагын —
Үкерә бер сәбәпсез.

Шундый буламыни инде
Мин «өйләнәсе» малай?
Андыйның акчасына да
Исем китми бик алай,
Чуртымамы машинасы,
Үзе тәртипсез булгач,
Яхшысын табармын әле,
Яшем зур булып тулгач.



## ТАТАРЧА СӨЙЛӘШЕРМЕН

Татарча гына сөйләш, дип,
Кисәтәм Диананы,
Зур үсеп, телең картайгач,
Өйрәнеп булмый аны.

Әни белән сөйләшәм, ди,
Әтием калган надан —
Ни эшләптер, әтиемә
Татарча тел чыкмаган.

Шулай булгач, ничек итеп
Татарча сөйләшәсең?
Инде тәмам аптырагач,
Русча гына дәшәсең.

Менә укый башлыйм әле —
Аңа да өйрәтермен,
Шул чагында мин һәрвакыт
Татарча сөйләшермен.



# СЫЙНЫФТАШЛАР

Беренче сыйныфка йөри
Укучы кыз Диана,
Йоклап калмыйм тагын, диеп,
Таң атуга уяна.



Бик әйбәтләп юына да
Чәчләрен тарап куя,
Китапларын, дәфтәрләрен
Яңадан барлап куя.

Җитез генә ашап алгач,
Җәһәт кенә киенә,
Ул арада кереп җитә
Сыйныфташы Алинә.

Әй серләшәләр икәүләп,
Чырык-чырык көләләр,
Соңга каласыз бит, дигәч,
Тиз чыгып йөгерәләр.

Дәресләр беткәч, шулай ук
Кулларны кулга салып,
Кайталар икәү парлашып,
Тик бераз арып, талып.



# КЫЗЫЛ КҮЗЛӘР

— Син бу малайның күзләрен
Ник буядың кызылга?—
дип сорады онытыннан
аптырагач дәү әнисе,
Сүзен сузмый озынга.

— И, дәү әни, син нәрсә,
Малайның янында торган
Матур кызны күрмәскә,
Яраткан күзләрдә һәрчак
Ут януын белмәскә?!

Бергә укып йөрер өчен
Әй көткәндер бу көзне,
Яңа костюмнарын киеп,
Чәчәкләр күтәреп килгән
Котларга дип шул кызны.

Кара менә: яратуы
Кызга гөл булып ява,
Шуңа күрә күзләре дә,
Шат елмайган йөзләре дә
Кызыл ут булып яна.



## ДИАНА ТӨШЕ

Тәрәзәгә күз салдым —
Бик нык гаҗәпкә калдым:
Бозау хәтле сап-сары эт
Яфрагын җыеп талның
Әй кереште күшәргә,
Инде миңа нишләргә?

Чакырыйммы этине,
Әллә табиб дәшимме?
Югыйсә, тал-тирәкләрне
Харап итә бит инде.

Менә сиңа тамаша:
Әллә күзем алдаша?
Күзне ныграк ачкан идем
Төш күрәм икән ләса.



## КЕШЕ ИТӘМ БАРЫБЕР!

Диләә исемле сеңлем бар —
Шундый тәртипсез бала:
Кулындагы һәр нәрсәне
Килә дә чәйгә сала,

Бармагын тыгып болгата
Чынаяктагы сөтен,
Маймыл кебек пычранса да,
Юдырып булмый битен.

Беркөн шулай үзе генә
Калган иде бүлмәмдә:
Әйтерсең, өермә узган —
Бөтен нәрсә идәндә.

Китап-дәфтәрләремне дә
Пыран-заран китергән,
Көндәлегемнең һәр битен
Сызып-буяп бетергән.

Ачуланган сүзләргә дә
Артык исе китмидер,
Аның артыннан җыярга
Ун әни дә җитмидер.

Җыйнаулап җыештырабыз
Бер Диләә туздырганны,
Әйткәнне дә һич тыңламый —
Көтә ул «кыздырганны».

Төземем бетсә, әйбәтләп
«Өйрәтермен» әле бер:
Бик шәпләп тәртипкә кертәм,
Кеше итәм барыбер.

# ӘСКӘР КИТАП УКЫЙ

Кечкенә булса да Әскәр,
Бик ярата китапны:
Укып чыга һәрбер сүзен,
Шигырьләрен дә ятлый.

Хәрефләр тора биешеп,
Әскәр мине күрсен, дип,
Ул бит шундый әйбәт малай,
Укый-укый үссен, дип.

Зур үскәч, үзе дә язар —
Менә күрерсез әле,
Һәрбер сүзен гөлләр итеп,
Бәйләм үрерсез әле.

## АТКАЕМ

Ак аткаем, туп-туп итеп,
Җилне тотам дип чаба,
Ә җил кинәт борылып исә
Ак аткаема таба.

Шулай куышып уйныйлар
Атым белән шаян җил.
Бергәләшеп шатланырбыз
Безнең янга син дә кил.





## ШЕРХАН

Безнең ата мәченең
Исеме матур — Шерхан,
Көннәр буе кәнәфидә —
Әйтерсең лә зур бер хан.

Әнием биргән каймакка
Бер дә исе китмидер,
Кич җиттеме — геройланып,
Күсе-тычкан эзлидер.

Өй тирәсендә булмаса,
Абзар янына бара,
Дошман солдатын кырган күк,
Аларны кырып сала.

## АПАМ

Теле үткен пычак кебек
Олы апамның минем,
Йомшарып китмәсен диптер,
Гел чарлап тора телен.

Беркөн урамга җыендым:
Аякта — киезката,
«Дәресеңне әзерлә!»— дип,
Боерык биреп ята.

Ә беркөнне, йокым туйгач,
Чыксам иртәнге ашка,
Кире борып кертмәсенме,
«Урныңны җый,— дип,— башта».

Кичә генә чыккан идем
Кичен кызлар янына,
«Әүвәл борныңны сөрт»,— диеп,
Тозлар салды каныма.



Дуслар, дими, кызлар, дими,
Һаман мине кимсетә,
Кулы белән тими үзе —
Теле белән эт итә.

Мәктәпкә киттем беркөнне,
Башка эшләпә киеп.
Кеше алдында хурлады:
«Ычкындың мәллә?»— диеп.

Уйлап-уйлап тордым да мин,
Чынлап торып «ычкындым»,
Күпме төзәргә була, дип,
Инде үзем кычкырдым:

«Тәртип тә синеңчә булыр,
Укуым да яхшырыр,
Син дигәнчә йөрсәм, бәлки,
Пычак телең тик торыр».





## ДАВЫЛ

Әни һаман әйтә килә:
«Син, улым, артык котырма,
Сеңелеңә дә тимә,
Әтиең бер тузып китсә,
Йә чыгар җилле давыл,
Йә килер зур зилзилә».

Һәм бервакыт, көтмәгәндә,
Килде бит шушы давыл:
Түбәләрне алып атты,
Тәрәзләрне бәреп ватты,
Капкаларны каерып ачты,
Хәтта этләр кереп качты,
Әллә инде җил дә шашты —
Ду килде бөтен авыл.

Тик мин берни аңламадым,
Алдан берни сизмәдем:
Котырып та йөрмәдем бит,
Сеңелемә дә тимәдем,
Бар дөньяны куптарырлык
Эшләрне дә күрмәдем.
Әти нигә тузды микән,
Нигә килде зилзилә?
Инде нәрсә ошамады?—
Шуны беләсем килә.



## КЕМ ӘЙТЕП БИРӘ?

Һич туктый белмәде инде —
Коя да коя яңгыр,
Һәрбер болытта, валлаһи,
Меңәр чиләк су бардыр.

Бу кадәрле су ничекләр
Күктә җыела икән?
Ник елгадай агып төшми —
Әллә куера микән?

Өем-өем кучкыл болыт
Ничек тота бу суны?
Кайсыгызның башы эшли —
Кем әйтеп бирә шуны?



## АК БӘТИ

Мирбулатның шатлыгы зур —
Йокысыннан да татлы:
Әбисенең ак кәҗәсе
Ак бәти алып кайтты.

Кеп-кечкенә бәти белән
Гел уйнады Мирбулат:
Маңгайга маңгай терәшеп
Йөрделәр койма буйлап.

Вакыт үтте, бәти үсте,
Мөгезләр чыкты килеп:
Мирбулатны һәм кызларны
Сөзеп йөри, ду килеп.

Урамга һич чыгып булмый —
Сагалап кына тора,
Сиздермичә генә атлап
Килә дә бәреп ега.

Әй елый хәзер Мирбулат:
«Зур бит инде бу бәти,
Сөзмәсен, шуны нык итеп
Ачулан әле, әти!»

Әтисе хәйләкәр генә
Елмаеп әйтте шунда:
«Кемне ачуланырга соң,
Ә кем гаепле монда?»







## БЕЗ — БӨРКЕТ БАЛАЛАРЫ

Биек үрләрне яуларбыз —
Куркытмый кыя-тавы,
Тәвәккәл булып үсәрбез:
Без — бөркет балалары.

Алдынгылыкны бирмәбез —
Тырышлык кирәк бары,
Сынатмабыз беркайчан да:
Без — бөркет балалары.

Авырлыкларны җиңәрбез —
Бердәмлек кирәк бары,
Һәрчак ярдәмгә килербез:
Без — бөркет балалары.

Җил-давыллар да өркетми —
Кыюлык кирәк бары,
Гайрәтле булып үсәрбез:
Без — бөркет балалары.









# СЕРЛЕ ТАБИГАТЬ





## КЫШ БЕЛӘН ЯЗ БӘЙГЕСЕ

Яшел үлән, яшел яфрак —
Кар утравы ята ап-ак:
Кыш белән Яз алышалар —
Кайсы кемне китәр каплап?!

Бирешмәскә тырышса да,
Кар утравы һаман кими,
Ә шулай да гайрәтләнә —
Җиңеләсе бер дә килми.

Чакыра ул кар-буранны,
Яшеллекне күмсен, диеп —
Яңгыр аша яуган карлар
Тиз арада бетә эреп.

Кар утравына ярдәмгә
Салкын көннәр килеп җитә,
Тик алар да озак тормый —
Балкып чыккан Май кояшы,
Җылы кочагына алып,
Һәммәсен дә язга илтә.



## МАЙ БУРАНЫ

Кояшлы яңгыр сер түгел —
Кайсыбыз белми аны?
Ә мин быел күрдем менә
Кояшлы кар яуганны.

Яз шундый итеп шаярды:
Кояш балкып торганда,
Чак кына адашмый калдык
Дулап торган буранда.

Яшел кырлар һәм чыршылар
Минутта ап-ак булды,
Таң калып йөргәндә хәтта
Авызга да кар тулды.

Яз бик сәер килде быел:
Башта тунны салдырды,
Аннан кабат кар яудырып,
Талларга көрт сардырды,
Боз-чәчкәле Май бәйрәмен
Истәлеккә калдырды.



## УМЫРЗАЯ

Карлар эреп бетәр-бетмәс,
Кар сулары китәр-китмәс,
Умырзая баш калкыткан,
Көн җылысы җитәр-җитмәс.

Аз гомерле булса да ул,
Нинди чыдам, нинди көчле,
Яз сулары, язгы җилләр
Бирәдер аңа бу көчне.

Яшәсә дә берничә көн,
Гомерләре булмас зая:
Яз килүгә ямь өләшә
Көлеп торган умырзая.



## ТУЗГАНАК

Сары чәчәк ап-ак башлы
Тузганак булды,
Шук җил исеп киткән иде
Йөзләгән парашют белән
Бөтен кыр тулды.

Үз артыннан еракларга
Дәшәләр алар:
«Безнең кебек очыгыз да
Әйләнеп кире кайтыгыз,
Гизеп дөньялар».







## МАЛАЙЛАР ГӘП КОРАЛАР

Ниндие юк яңгырның дип,
Гәпләшәләр малайлар:
Хәйран җитди кыланалар —
Әйтерсең лә агайлар.

Әскәр әйтә: — Минем сүзне
Раслар абый-апалар:
Кызыл, сары яңгыр була,
Ява хәтта бакалар.

Яңгыр яуса ишеп-ишеп,
Җир белән күк тоташа,
Ни дә булса күрим димә
Яңгыр пәрдәсе аша.

— Чыбыркылап яуса әгәр, —
ди сыбызгы асканы, —
Сикерә-сикерә йөгерәсең,
Белми кая басканны.

Сибәләп яуганы — явыз:
Көне буена бара,
Әле кайчак, эч пошырып,
Таңга кадәр дә кала.

— Кояшлы яңгыр, — ди Әхәт,
Бәреп ява да китә,
Качып өлгермәсәң, ул да
Коендырып эт итә.

Әбер-чобыр чапкан була,
Бөрешкән чебеш кебек,
Апалар да, әбиләр дә
Йөгерә терек-терек.

Ә безгә ни — безгә рәхәт:
Һич ашыкмыйбыз өйгә,
Яңгыр бетеп, су ерганда,
Күлмәк-ыштан да кибә.

— Тик яшенлесе, — ди Әнвәр —
Бераз гына шүрләтә,
Өй эчендә шактый йөртә,
Ишекле дә түрләтә.

Тәрәзне ачык калдырсаң,
Җил сыный башлый көчен,
Ишекне ябып биклисең,
Яшен кермәсен өчен.

Бисмилланы әйтә-әйтә,
Посасың мич артына,
Яңгыр тәмам туктаганчы
Утырасың калтырап.

— Ә мин,— диде бер шук малай,—
Куркып тормыймын бер дә,
Дөбер-шатыр килгәндә дә
Чыгам да китәм өйдән.

— Утырма сана, — диде Вил,—
Мин курыкмыймын, диеп,
Ник алайса кача-поса
Йөрисең бүрек киеп?

Өйдән чыгу сиңа тагы —
Сөяге юк шул телнең,
Үзен нигә мин кергәндә
Юрган астында идең?

Ык-мык килде дә шук малай,
Читкә барып утырды,
Мактанмакчы иде бераз,
Тик ялганы тотылды...

Коеп яуган яңгырдан соң
Малайлар гәп коралар,
Бер читтәрәк зур агайлар
Сүзгә катышмыйча гына
Көлеп тыңлап торалар.





## ҖӘЙГЕ КОЯШ

Кояш бигрәк шәп кыздыра —
Бирә генә кирәкне,
Бөтен җирем шыр су булды
Мунчасы да кирәкми.

Көнозын кояшта йөреп,
Чуен кебек каралдым,
Кичен өйгә кайтып керсәм,
Бәлеш кебек таралдым.

Гәүдәмне һич җыя алмыйм,
Башым ут булып яна.
Әни әйтә: «Сиңа бүген
Кояш суккан бит, бала».

Бәрәч, кулсыз кояшның да
Бар микәнни тукмагы,
Алайса, ник сизмәдем соң
Мине тотып тукмавын?



# КИТТЕМ БАЛЫК ТОТАРГА

Әти-әни күргәнче, дип,
Иртүк, таң белән торып,
Тиз киттем балык тотарга.
Юл буе хәйлә корып.

Бара торгач, килеп җиттем
Балыклы Якты күлгә,
Хәйләм бер дә булышмады —
Балык эләкми бер дә.

Кечкенә дип үртәшәдер
Күлдәге чабак балык,
Килә дә койрык күрсәтә —
Бигрәк әдәпсез халык.

Ялынып тормыйимчы әле,
Зурлар белән килермен,
Инде ничек хурланмыйча
Өйгә кайтып керермен.

Әй, тукта әле, дидем дә
Туры киттем инешкә...
«Маймыч тоттым,—
дип мактандым,
Өйгә керә-керешкә.



## ЯҢГЫР

Яңгыр коя чиләкләп,
Боз дөмбәсли түбәне,
Уйнап йөргән бөтен бала
Кереп качты, күр әле!

Урам әйләнде елгага —
Йөзеп йөри машина,
Зур агачлар шау кыйләләр,
Яулык эзләп башына.

Әй ялвара балалар,
Качкан кояшка карап:
«Җитте инде бу яңгырга,
Чык та болытны тарат».





## УЧАК ЯНЫНДА

*(тел чарлагыч)*

Беркөн шулай, җыелышып,
Киттек күлле урманга:
Суда йөзеп, үләнендә
Тәгәрәшеп уйнарга.

Такыр юлдан элдертәбез —
Кояш шактый кыздыра:
Башны тәмам аңгырайта,
Уйларны да туздыра.

Барып җиттек хәйран пешеп,
Әйләнмәс булды тел дә,
Аланда туктап тормадык —
Туры киттек зур күлгә.

Килә-килүк күлгә чумдык —
Чыгасы килми судан,
Хәлләр киткәнче йөзелгән,
Иреннәр күм-күк булган.

Үтерeп ашыйсы килгәч,
Ярга чыктык үрмәләп,
Ятып бераз ял иттек тә
Ашап алдык бергәләп.

Инде учак якмак булдык
Табигать кочагында,
Шырпыбыз дымланган икән —
Кабынмый, пычагым да.

Кояшта киптереп алдык
Иң әүвәле шырпыны, —
Сыздык кына — ут ялмады
Якын торган чыршыны.

Тиз-тиз киемнәрне салып,
Әй кыйныйбыз ялкынны,
Котлар очты, һич сизмибез
Эссене, ни салкынны.

Корымга буялып беттек —
Бирешми бит бу явыз,
Утны йөгәнләп йөргәндә,
Пәри кебек булганбыз.

Дөрләгән ут көчкә сүнде —
Башка учак якмадык,
Әйберләрне җыйнадык та
Кайтыр юлдан атладык.







## ҖӘЙНЕҢ МАТУР БЕР ЧАГЫ

Тук башаклар чайкалалар,
Бер-беренә сыенып,
Очып-очып сайрый тургай,
Мул уңышка сөенеп.

Алтын төскә керде арыш,
Бодае һәм борчагы,
Игеннәр өлгергән вакыт —
Җәйнең матур бер чагы.



## КӨЗ

Караеп калды киң кырлар
Игеннәр җыелгач та,
Җәй айларындагы кебек
Бик кыздырмый кояш та.

Күк тә инде зәңгәр түгел,
Болында — кылган-түшәк,
Күбәләктәй оча-оча,
Сап-сары яфрак төшә.

## КАЛСЫН ХӘТЕРДӘ

Дәфтәремне алып, битләренә
Киң кырларны ясап куярмын,
Дулкын-дулкын килгән арышларны
Алтын-сары төскә буярмын.

Бормаланып зәңгәр инеш агар,
Яшел үзәннәрне буйлатып,
Аны куып, челтер-челтер килер
Чишмәбездән чыккан елгачык.

Гүзәллекне мактап сайрап очкан
Тургайлар да булыр рәсемдә:
Туган якның матур табигате
Мәңге калсын иде хәтердә.





## ГӨМБӘГӘ

Агачлары күккә тигән зур урманга
Гөмбәгә дип килдек шулай без бервакыт:
Ап-ак каен эргәсендә бер яшь гөмбә
Эшләпәсен җилпеп тора, үрә катып.

Тубыгына кадәр җиткән зур җиләннән
Төп гөмбәсе тезелешкән, рәт-рәт булып,
Җыеп алдым һәммәсен дә, җайлап кына,
Шуның белән кәрзинем дә китте тулып.

«Кызым, бүген син бигрәк тә тырышсың»,— дип,
Дәү әнием мактап куйды, үссендереп,
Кайткан чакта, хәлдән таеп арыса да,
Сер бирмичә, егетләрчә түзсен, диеп.



## НӘКЪ ӘКИЯТ, ДИЯРСЕҢ

Кышның бозлы таулары,
Шыгыр-шыгыр карлары,
Тәрәздәге бизәкләре,
Чыршыдагы шарлары —
Бар да матур, тылсымлы,
Нәкъ әкият, диярсең,
Шушындый гүзәл дөньяны
Сөймәс җирдән сөярсең.

## УЙНАКЛАШЫП КАР ЯВА

Иртән торсам, хәйран калдым
Тышта сап-салкын һава,
Тамчы-тамчы яңгыр белән
Уйнаклашып кар ява.

Кайчагында кар бөртеге
Килеп куна тамчыга,
Тамчы, явыз, аны йота —
Кардан калмый тамчы да.







## КЫШКЫ ТӨН

Кышкы төндә ай җыр суза:
Анда — йолдызлар дәрте,
Челтәрле чыршылар моңы,
Шәрә таллар хәсрәте.

Салкын айның яктысында
Ак каеннар моңлана,
Өзелми калган яфраклар
Туңудан калтырана.

Кышкы төн — гаҗәп күренеш,
Табигатьнең бер сере,
Урман, айның, йолдызларның
Җырга әйләнгән төре.

## УЙНАВЫ РӘХӘТ ТЫШТА

Дәресемне әзерләгәч,
Киендем дә тиз генә,
Дуслар янына уйнарга
Элдердем җитез генә.

Урам матур, чип-чиста,
Уйнавы рәхәт тышта,
Тәгәрәшеп тау шуабыз,
Рәхмәтләр әйтеп кышка.



ЭЧТӘЛЕК

**Тылсымлы кошчык**

Сөйдергеч бөтие . . . . . . . . . . 4
Нәни Дилә . . . . . . . . . . 4
Тылсымлы кошчык . . . . . . . . . . 5
Ярдәмгә куша кулны . . . . . . . . . . 6
«Өйләнсәм», ни диярсең? . . . . . . . . . . 8
Татарча сөйләшермен . . . . . . . . . . 9
Сыйныфташлар . . . . . . . . . . 10
Кызыл күзләр . . . . . . . . . . 11
Диана төше . . . . . . . . . . 12
Кеше итәм барыбер! . . . . . . . . . . 13
Әскәр китап укый . . . . . . . . . . 14
Аткаем . . . . . . . . . . 15
Шерхан . . . . . . . . . . 16
Апам . . . . . . . . . . 17
Давыл . . . . . . . . . . 19
Кем әйтеп бирә? . . . . . . . . . . 20
Ак бәти . . . . . . . . . . 21
Без — бөркет балалары . . . . . . . . . . 22

**Серле табигать**

Кыш белән яз бәйгесе . . . . . . . . . . 24
Май бураны . . . . . . . . . . 25
Умырзая . . . . . . . . . . 26
Тузганак . . . . . . . . . . 27
Малайлар гәп коралар . . . . . . . . . . 29
Җәйге кояш . . . . . . . . . . 31
Киттем балык тотарга . . . . . . . . . . 32
Яңгыр . . . . . . . . . . 33
Учак янында . . . . . . . . . . 34
Җәйнең матур бер чагы . . . . . . . . . . 35
Көз . . . . . . . . . . 36
Калсын хәтердә . . . . . . . . . . 36
Гөмбәгә . . . . . . . . . . 37
Нәкъ әкият, диярсең . . . . . . . . . . 38
Уйнаклашып кар ява . . . . . . . . . . 38
Кышкы төн . . . . . . . . . . 39
Уйнавы рәхәт тышта . . . . . . . . . . 39



Издание для детей и юношества

Флёра Тарханова

*(Тарханова Фёра Габдрахмановна)*

ЗАГАДОЧНЫЙ МИР

*(на татарском языке)*

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*

Нәшриятка 04184 нче лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.08.2002.
Форматы 60×90 1/8. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 5,0+форз. 0,5. Шартлы-буяу оттиск 23,0. Нәшер-хисап табагы 5,46+форз.0,88.
Тиражы 5000. Заказ Б-434.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы» дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.